КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 4 август г.Казань № 565

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2030 елга кадәр Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексын үстерү стратегиясен раслау турында» 2024 ел, 6 сентябрь, 733 нче карары белән расланган 2030 елга кадәр Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексын үстерү стратегиясенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2030 елга кадәр Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексын үстерү стратегиясен раслау турында» 2024 ел, 6 сентябрь, 733 нче карары белән расланган 2030 елга кадәр Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексын үстерү стратегиясенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

I бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«I. Гомуми нигезләмәләр

Стратегия Татарстан Республикасы социаль-икътисади үсеш максатларын һәм бурычларын, Россия Федерациясенең агросәнәгать комплексы үсешен, илкүләм үсеш максатларын һәм Татарстан Республикасының аларга ирешүгә керткән өлешен исәпкә алып әзерләнде.

Стратегиянең төп билгеләнеше – аграр җитештерүне интенсификацияләү, авыл хуҗалыгы продукциясен һәм азык-төлек продуктларын эшкәртүне үстерү һәм экспортлауны арттыру исәбенә азык-төлек һәм икътисадый иминлекне тәэмин итү өчен яңа геосәяси шартларда Татарстан Республикасының дәүләт сәясәте

өстенлекләрен билгеләүдән гыйбарәт.

Стратегиянең максаты – нәтиҗәлелеген һәм конкуренциягә сәләтен арттыру нигезендә Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексының алгарышлы үсешен тәэмин итү.

Стратегия 2030 елга кадәр чорга Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатларын, 2030 елга кадәр чорга Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерүнең стратегик максатларын һәм өстенлекләрен исәпкә алып эшләнде һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының стратегик планлаштыруның төп документлары белән синхронлаштырылды.

Стратегия Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексын үстерүгә юнәлдерелгән проектларны һәм чараларны үз эченә алган Татарстан Республикасы дәүләт программаларын, стратегик планлаштыру буенча башка төбәк һәм муниципаль документларын эшләү өчен нигез булып тора.

Стратегия түбәндәгеләрне исәпкә алып эшләнде:

«Авыл хуҗалыгын үстерү турында» 2006 елның 29 декабрендәге 264-ФЗ номерлы Федераль закон;

«Авыл хуҗалыгы иминияте өлкәсендә дәүләт ярдәме турында һәм «Авыл хуҗалыгын үстерү турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2011 елның 25 июлендәге 260-ФЗ номерлы Федераль закон;

«Россия Федерациясендә стратегик планлаштыру турында» 2014 елның 28 июнендәге 172-ФЗ номерлы Федераль закон;

«Органик продукция турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 3 августындагы 280-ФЗ номерлы Федераль закон;

Россия Федерациясе Президентының «2017 – 2030 елларга Россия Федерациясендә мәгълүмат җәмгыятен үстерү стратегиясе турында» 2017 елның 9 маендагы 203 номерлы Указы;

Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясенең азык-төлек иминлеге доктринасын раслау турында» 2020 елның 21 гыйнварындагы 20 номерлы Указы;

Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясенең илкүләм иминлеге стратегиясе турында» 2021 елның 2 июлендәге 400 номерлы Указы;

Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә стратегик планлаштыру өлкәсендә дәүләт сәясәте нигезләрен раслау турында» 2021 елның 8 ноябрендәге 633 номерлы Указы;

Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясенең климат доктринасын раслау турында» 2023 елның 26 октябрендәге 812 номерлы Указы;

Россия Федерациясе Президентының «2030 елга кадәрге чорга һәм 2036 елга кадәрге перспективага Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатлары турында» 2024 елның 7 маендагы 309 номерлы Указы;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 29 июнендәге б-1364 номерлы боерыгы;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 7 июлендәге б-1455 номерлы боерыгы;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 10 августындагы б-1796 номерлы боерыгы;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 30 августындагы

б-1931 номерлы боерыгы;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 6 июнендәге б-1512 номерлы боерыгы;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 1 октябрендәге б-2765 номерлы боерыгы;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 8 сентябрендәге б-2567 номерлы боерыгы;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 20 маендагы б-1315 номерлы боерыгы;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 4 июлендәге б-1788 номерлы боерыгы;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 23 ноябрендәге б-3309 номерлы боерыгы;

«2022 – 2030 елларга авыл хуҗалыгы өлкәсендә калдыклардан икенчел ресурслар һәм икенчел чимал куллану» тармак программасының 2022 елның 29 декабрендәге 16133п-П11 номерлы паспорты;

Татарстан Республикасы Бюджет кодексы;

«Татарстан Республикасында стратегик планлаштыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 12-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

«2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясен раслау турында» 2015 елның 17 июнендәге 40-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

«Татарстан Республикасының азык-төлек иминлеге турында» 2017 елның 13 июлендәге 53-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

«Татарстан Республикасында органик продукция җитештерүне үстерү турында» 2021 елның 5 маендагы 34-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясен гамәлгә ашыру чаралары планын раслау турында» 2015 ел, 25 сентябрь, 707 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 – 2025 елларга Татарстан Республикасында кулланучылар кооперациясен үстерү концепциясен раслау турында» 2021 ел, 6 февраль, 60 нчы карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 – 2025 елларга Татарстан Республикасында кулланучылар кооперациясен үстерү концепциясен гамәлгә ашыру чаралары планын раслау турында» 2021 ел, 25 март, 165 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының икътисад тармакларын, социаль өлкә һәм дәүләт идарәсен цифрлы трансформацияләү өлкәсендәге стратегиясен раслау турында» 2021 ел, 18 август, 748 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2030 елга кадәр Татарстан Республикасында экспорт эшчәнлеген үстерү өчен уңайлы шартлар тәэмин итү стратегиясен раслау турында» 2023 ел, 28 декабрь, 1701 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2025 елга Татарстан

Республикасы Рәисенең Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Юлламасын гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең комплекслы гамәлләр планы турында» 2024 ел, 17 декабрь, 1155 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 16 май, б-1073 нче боерыгы;

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының «Стратегияне раслау турында» 2017 елның 21 июлендәге 165/2-пр номерлы боерыгы;

2025 елга Татарстан Республикасы Рәисенең Татарстан Республикасы Дәүләт Советына юлламасы.»;

VII бүлектә:

7.1 бүлекчәне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.1. Эшкәртү

Сыйфатлы һәм кирәкле азык-төлек продуктлары, шулай ук авыл хуҗалыгы чималын һәм икенчел ресурсларны (калдыкларны) эшкәртү барышында алына торган югары өстәлгән кыйммәткә ия башка продукция җитештерү күләмнәрен һәм ассортиментын арттыру буенча стратегик бурычны хәл итүгә түбәндәге үсеш юнәлешләрен гамәлгә ашыру ярдәм итәчәк:

гамәлдәге эшкәртү предприятиеләрен техник яктан яңадан җиһазлау һәм модернизацияләү һәм яңаларын төзү (шул исәптән федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән);

авыл хуҗалыгы продукциясен, беренче чиратта ашлык һәм сөтне тирәнтен эшкәртүне үстерүне тәэмин итү өчен өчен шартлар тудыру;

яшелчә һәм җиләк-җимеш продукциясен эшкәртү производстволарын оештыру;

чыгарыла торган продукция ассортиментын продуктларның азык-төлек һәм биологик кыйммәтен арттыра торган заманча технологияләрне кертү исәбенә киңәйтү;

экологик чиста һәм имин продукция җитештерү өчен фәннең иң яңа казанышларыннан файдалану;

яңа буын төргәкләү материалларын, шул исәптән Татарстан Республикасы символикасы белән куллану, чыгарыла торган продукциянең товар төрен яхшырту;

Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексы тармагы продукциясенә базар сыйдырышлылыгын һәм ихтыяҗын өйрәнү буенча маркетинг тикшеренүләрен уздыру, продукциянең яңа төрләрен эшләгәндә һәм кулланышка керткәндә тикшеренүләр мәгълүматларын исәпкә алу;

төбәк, бөтенроссия һәм халыкара күргәзмәләрдә һәм конкурсларда эшкәртү предприятиеләре актив катнашу;

чимал һәм продукция саклау мөмкинлекләрен (сроклар буенча) киңәйтүгә китерә торган инфраструктура һәм логистик тәэмин итүне үстерү;

эшкәртү предприятиеләре эшләгән зонада әйләнә-тирә мохиткә экологик йөкләнешне киметү;

«Критик әһәмиятле фермент препаратлары, азык-төлек һәм азык өстәмәләре, технологик ярдәмче чаралар җитештерү» федераль проекты кысаларында критик

әһәмиятле фермент препаратлары, азык-төлек һәм азык өстәмәләре, технологик ярдәмче чаралар җитештерү өлкәсендә технологик бәйсезлекне тәэмин итү.

Авыл хуҗалыгы продукциясен тирәнтен эшкәртү өлкәсендә өстенлекле үсеш юнәлешләре:

ашлыкны һәм сөтне тирән эшкәртүне тәэмин итә торган инновацион технологияләрне кертү;

сусле культураларны (җитен, техник киндерне) тирәнтен эшкәртүне оештыру;

тирәнтен эшкәртү буенча инвестиция проектларын гамәлгә ашыруга дәүләт ярдәме чаралары күрсәтү;

тирән эшкәртү өлкәсендә проектларны гамәлгә ашыру өчен кооператив структуралар булдыруны стимуллаштыру;

тирәнтен эшкәртү өлкәсендә проектларны гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексы субъектларына мәгълүмати-консультация ярдәме күрсәтү.

Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек сәнәгатендә барлыкка килә торган икенчел ресурсларны (калдыкларны) эшкәртү өлкәсендә өстенлекле юнәлешләр:

авыл хуҗалыгы калдыкларын, авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерү калдыкларын һәм биологик калдыкларны, терлекчелекнең өстәмә продуктларын утильләштерү (эшкәртү) инфраструктурасын үстерү;

авыл хуҗалыгы калдыкларыннан альтернатив ягулыкка нигезләнгән кечкенә энергетиканы үстерү;

терлекчелек өчен азык продуктлары, фармацевтика сәнәгате өчен, шулай ук башка юнәлешләрдә файдалану өчен чимал алып, ярма һәм атланмай-май җитештерү калдыкларын утильләштерү технологияләрен кертү;

терлекчелек өчен азык базасын булдыру, азык-төлек һәм эшкәртү, химия һәм фармацевтика тармакларында продукция җитештерү өчен шикәр сәнәгатенең икенчел ресурсларын (чөгендер түбен һәм меласcасын) хуҗалык әйләнешенә җәлеп итү;

төрле продукция җитештерү өчен ит сәнәгатенең өстәмә чимал ресурсларын (тире, эчәк, кан, сөяк, эндокрин-фермент һәм махсус чимал һ.б.) җыюны һәм эшкәртүне арттыру;

сөт продуктлары җитештергәндә алына торган икенчел ресурсларны (майсызландырылган сөт, май әйрәне һәм сөт суы) эшкәртү технологияләрен кертү.»;

7.3 бүлекчәнең икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Алдынгы технологияләрне һәм инновацияләрне кулланышка кертү нигезендә Татарстан Республикасының агросәнәгать комплексы эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыру буенча стратегик бурычны хәл итүгә «Азык-төлек иминлеген технологик тәэмин итү» илкүләм проектының «Татарстан Республикасының фәнни-технологик үсеше» Татарстан Республикасы дәүләт программасының «Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексын интенсификацияләү» төп технологик трегын гамәлгә ашыру юнәлешләре белән синхронлаштырылган түбәндәге юнәлешләрен гамәлгә ашыру ярдәм итәчәк:»;

7.4 бүлекчәнең беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Агросәнәгать комплексында кадрлар» федераль проекты нигезендә Татарстан Республикасының агросәнәгать комплексын яңа технологияләр һәм инновацияләр белән эшләүгә әзерләнгән квалификацияле кадрлар белән тәэмин итү буенча

стратегик бурычны хәл итүгә түбәндәге үсеш юнәлешләрен гамәлгә ашыру ярдәм итәчәк:»;

әлеге Стратегиягә 1 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

әлеге Стратегиягә 2 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

2030 елга кадәр Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексын үстерү стратегиясенә 1 нче кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 4 август, 565 нче
карары редакциясендә)

## Максатчан күрсәткечләрнең фараз күрсәткечләре, үсешнең төп күрсәткечләре

| Стратегик максатлар, бурычлар, максатчан күрсәткечләр, үлчәү берәмлеге | 2022 ел (база) | 2023 ел | I этап | | | II этап | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел | 2029 ел | 2030 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
| Стратегик максат: Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексының нәтиҗәлелеген һәм конкурентлык сәләтен арттыру нигезендә аның алдан үсешен тәэмин итү | | | | | | | | | |
| Агросәнәгать комплексы продукциясен җитештерү индексы (чагыштырма бәяләрдә) 2022 ел дәрәҗәсенә карата, процент | | | | | | | | | |
| База | 100,0 | 99,8 | 106,0 | 108,3 | 110,7 | 113,2 | 115,7 | 118,3 | 120,9 |
| Максатчан | 100,0 | 99,8 | 107,0 | 109,8 | 112,7 | 117,3 | 122,1 | 127,1 | 132,4 |
| 2022 ел дәрәҗәсенә карата барлык категорияләрдәге хуҗалыкларда авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерү индексы (чагыштырма бәяләрдә), процент | | | | | | | | | |
| База | 100,0 | 92,1 | 101,9 | 103,8 | 105,8 | 107,7 | 109,8 | 111,8 | 113,9 |
| Максатчан | 100,0 | 92,1 | 103,4 | 105,6 | 107,8 | 110,1 | 112,4 | 114,8 | 117,2 |
| 2022 ел дәрәҗәсенә карата азык-төлек продуктлары җитештерү индексы (чагыштырма бәяләрдә), процент | | | | | | | | | |
| База | 100,0 | 105,5 | 108,2 | 111,1 | 113,9 | 116,9 | 119,9 | 123,1 | 126,3 |
| Максатчан | 100,0 | 105,5 | 108,7 | 112,1 | 115,5 | 122,4 | 129,6 | 137,2 | 145,3 |
| 2022 ел дәрәҗәсенә карата эчемлекләр җитештерү индексы (чагыштырма бәяләрдә), процент | | | | | | | | | |
| База | 100,0 | 99,9 | 100,5 | 102,6 | 104,8 | 107,0 | 109,2 | 111,5 | 113,8 |
| Максатчан | 100,0 | 99,9 | 101,3 | 104,8 | 108,5 | 114,0 | 119,9 | 126,0 | 132,4 |
| Татарстан Республикасының тулаем төбәк продуктында «Авыл хуҗалыгы, | | | | | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| урман хуҗалыгы, аучылык, балык тоту һәм балыкчылык» дигән эшчәнлек төре буенча тулаем өстәлгән кыйммәт өлеше, процент | | | | | | | | | |
| База | 4,7 | 3,9 | 4,70 | 4,72 | 4,67 | 4,62 | 4,57 | 4,51 | 4,46 |
| Максатчан | 4,7 | 3,9 | 4,94 | 4,96 | 4,98 | 5,00 | 5,00 | 5,00 | 5,00 |
| Татарстан Республикасының тулаем төбәк продуктында «Азык-төлек продуктлары җитештерү» һәм «Эчемлекләр җитештерү» дигән эшчәнлек төрләре буенча тулаем өстәлгән кыйммәт өлеше, процент | | | | | | | | | |
| База | 1,38 | 1,61 | 1,64 | 1,68 | 1,72 | 1,83 | 1,90 | 2,0 | 2,0 |
| Максатчан | 1,38 | 1,61 | 1,71 | 1,75 | 1,80 | 1,86 | 1,95 | 2,5 | 3,0 |
| 1 нче стратегик бурыч. Эшкәртү: авыл хуҗалыгы чималын һәм икенчел ресурсларны (калдыкларны) эшкәртү барышында югары өстәлгән кыйммәткә ия сыйфатлы һәм таләп ителә торган азык-төлек продуктлары, шулай ук башка продукция җитештерү күләмен һәм ассортиментын арттыру | | | | | | | | | |
| Бөртекне тирәнтен эшкәртү күләме, мең тонна | | | | | | | | | |
| База | - | - | - | - | - | - | - | - | - |
| Максатчан | - | - | - | - | - | 250,0 | 500,0 | 750,0 | 1 000,0 |
| Сөтне тирәнтен эшкәртү күләме, мең тонна | | | | | | | | | |
| База | - | - | - | - | - | - | - | - | - |
| Максатчан | - | - | - | - | - | 50,0 | 100,0 | 250,0 | 500,0 |
| Критик әһәмиятле фермент препаратлары, азык-төлек һәм азык өстәмәләре, технологик ярдәмче чаралар җитештерү буенча гамәлдәге куәтләрнең артуы, тонна | | | | | | | | | |
| База | - | - | - | - | - | - | - | 9 | 42 |
| Максатчан | - | - | - | - | - | - | - | 9 | 42 |
| 2 нче стратегик бурыч. Сату һәм экспорт: Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексы продукциясенең төбәкара һәм глобаль базарларда конкурентлык сәләтен, тотрыклы һәм гарантияле сатуны һәм Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексының экспорт потенциалын үстерүне тәэмин итү | | | | | | | | | |
| Татарстан Республикасының агросәнәгать комплексы продукциясен экспортлау, АКШ млн. доллары | | | | | | | | | |
| База | 444,9 | 457,6 | 457,6 | 509,3 | 566,8 | 630,9 | 702,2 | 781,5 | 869,8 |
| Максатчан | 445,1 | 457,6 | 457,6 | 531,7 | 617,9 | 718,0 | 834,3 | 969,4 | 1 126,5 |
| 3 нче стратегик бурыч. Технологияләр һәм инновацияләр: Алдынгы технологияләрне һәм инновацияләрне кертү нигезендә Татарстан Республикасының агросәнәгать комплексы эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыру | | | | | | | | | |
| Авыл хуҗалыгы культураларының иген кырының бер өлешендә оригиналь һәм элита орлыклар чәчелгән мәйдан өлеше, процент | | | | | | | | | |
| База | 38,0 | 36,0 | 30,0 | 30,0 | 30,0 | 30,0 | 30,0 | 30,0 | 30,0 |
| Максатчан | 38,0 | 36,0 | 30,0 | 30,0 | 30,0 | 30,0 | 30,0 | 30,0 | 30,0 |
| Мөгезле эре терлекнең гомуми баш санында продуктив сөт юнәлешендәге | | | | | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| мөгезле эре терлекнең нәселле баш санының чагыштырма авырлыгы, процент | | | | | | | | | |
| База | 29,3 | 29,3 | 29,3 | 29,3 | 29,3 | 29,3 | 29,3 | 29,3 | 29,3 |
| Максатчан | 29,3 | 29,3 | 29,3 | 29,3 | 29,3 | 29,3 | 29,3 | 29,3 | 29,3 |
| Азык үзәкләренең куәтен кулланышка кертү, тонна | | | | | | | | | |
| База | 998,0 | 969,0 | 950,0 | 900,0 | 850,0 | 800,0 | 750,0 | 700,0 | 650,0 |
| Максатчан | 998,0 | 969,0 | 950,0 | 950,0 | 900,0 | 850,0 | 800,0 | 750,0 | 700,0 |
| Сөт комплексларының куәтен кулланышка кертү, мең баш | | | | | | | | | |
| База | 18,0 | 10,6 | 6,6 | 4,4 | 4,0 | 4,0 | 4,0 | 4,0 | 4,0 |
| Максатчан | 18,0 | 10,6 | 6,6 | 6,0 | 6,0 | 6,0 | 6,0 | 6,0 | 6,0 |
| Балык үрчетү хуҗалыклары саны, берәмлек (арта бара торган йомгак белән) | | | | | | | | | |
| База | 14,0 | 14,0 | 15,0 | 16,0 | 17,0 | 18,0 | 20,0 | 20,0 | 22,0 |
| Максатчан | 14,0 | 14,0 | 16,0 | 17,0 | 18,0 | 24,0 | 24,0 | 24,0 | 24,0 |
| Балык утырту материалы күләме, тонна (еллык күрсәткеч) | | | | | | | | | |
| База | 423,0 | 332,0 | 356,0 | 379,0 | 403,0 | 427,0 | 470,0 | 500,0 | 510,0 |
| Максатчан | 423,0 | 332,0 | 366,0 | 392,0 | 417,0 | 444,0 | 490,0 | 535,0 | 575,0 |
| Товар балыгы күләме, тонна (еллык күрсәткеч) | | | | | | | | | |
| База | 645,0 | 595,0 | 638,0 | 680,0 | 723,0 | 765,0 | 850,0 | 935,0 | 1 020,0 |
| Максатчан | 645,0 | 595,0 | 656,0 | 723,0 | 796,0 | 877,0 | 967,0 | 1 066,0 | 1 174,0 |
| Үзйөрешле авыл хуҗалыгы техникасын яңарту, процент | | | | | | | | | |
| База | 3,8 | 5,7 | 5,0 | 5,0 | 5,0 | 5,0 | 6,0 | 6,0 | 7,0 |
| Максатчан | 3,8 | 5,7 | 5,2 | 5,5 | 6,0 | 7,0 | 8,0 | 9,0 | 10,0 |
| Тагылмалы авыл хуҗалыгы техникасын яңарту, процент | | | | | | | | | |
| База | 6,4 | 6,1 | 6,0 | 6,0 | 6,0 | 6,0 | 6,0 | 6,0 | 6,0 |
| Максатчан | 6,4 | 6,1 | 6,2 | 6,2 | 6,2 | 6,4 | 6,4 | 6,4 | 6,4 |
| Терлекчелек җиһазын яңарту, процент | | | | | | | | | |
| База | 3,0 | 3,1 | 3,5 | 3,5 | 3,5 | 3,5 | 3,5 | 3,5 | 3,5 |
| Максатчан | 3,0 | 3,1 | 3,5 | 3,5 | 3,5 | 3,5 | 3,5 | 3,5 | 3,5 |
| 4 нче стратегик бурыч. Кадрлар: Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексын яңа технологияләр һәм инновацияләр белән эшләргә әзерләнгән квалификацияле кадрлар белән тәэмин итү. | | | | | | | | | |
| Авыл хуҗалыгында (кече эшкуарлык субъектларыннан башка) реаль уртача айлык хезмәт хакының 2022 ел дәрәҗәсенә карата үсеш темпы, процент | | | | | | | | | |
| База | 100,0 | 111,6 | 121,9 | 133,5 | 145,6 | 158,2 | 171,2 | 184,8 | 198,8 |
| Максатчан | 100,0 | 111,6 | 123,6 | 136,3 | 149,6 | 163,4 | 177,8 | 192,9 | 208,7 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Авыл хуҗалыгында (кече эшкуарлык субъектларыннан башка) уртача айлык номиналь хезмәт хакының Татарстан Республикасы икътисады буенча уртача айлык хезмәт хакы белән нисбәте, процент | | | | | | | | | |
| База | 75,1 | 77,6 | 80,1 | 82,7 | 85,2 | 87,7 | 87,7 | 87,7 | 87,7 |
| Максатчан | 75,1 | 78,2 | 81,3 | 84,4 | 87,5 | 90,6 | 93,7 | 96,8 | 100,0 |
| Агросәнәгать комплексы предприятиеләренең 35 яшькә кадәрге яшь кадрлары өлеше, процент | | | | | | | | | |
| База | - | 0 | - | 9 | 10 | 11 | 12 | 14 | 15 |
| Максатчан | - | 0 | - | 9 | 10 | 11 | 12 | 14 | 15 |
| Аграр юнәлештәге фәнни учреждениеләрдә һәм югары белем бирү мәгариф оешмаларында гыйльми дәрәҗәләргә һәм исемнәргә ия хезмәткәрләрнең өлеше, процент | | | | | | | | | |
| База | - | 0 | - | 82 | 83 | 83 | 84 | 85 | 86 |
| Максатчан | - | 0 | - | 82 | 83 | 83 | 84 | 85 | 86 |
| Агросәнәгать комплексы тармагында 5 елдан артык эшләүче хезмәткәрләр өлеше, процент | | | | | | | | | |
| База | - | 0 | - | 89 | 90 | 91 | 92 | 93 | 94 |
| Максатчан | - | 0 | - | 89 | 90 | 91 | 92 | 93 | 94 |
| Аграр юнәлештәге фәнни учреждениеләрнең һәм югары белем бирү мәгариф оешмаларының фәнни һәм фәнни-педагогик хезмәткәрләре өчен торак урын наймы шартнамәсе буенча бирелә торган торак төзү (сатып алу) гамәлгә ашырылган әлеге хезмәткәрләр саны, кеше | | | | | | | | | |
| База | - | 0 | - | 13 | 47 | 78 | - | - | - |
| Максатчан | - | 0 | - | 13 | 47 | 78 | - | - | - |
| Агросәнәгать комплексы предприятиеләренең кадрлар белән тәэмин ителеше, процент | | | | | | | | | |
| База | - | 0 | - | 90 | 90 | 91 | 92 | 93 | 95 |
| Максатчан | - | 0 | - | 90 | 90 | 91 | 92 | 93 | 95 |
| 5 нче стратегик бурыч. Цифрлаштыру: Цифрлы технологияләр һәм платформа чишелешләрен гамәлгә кертү нигезендә Татарстан Республикасының агросәнәгать комплексы белән идарә итү арттыру | | | | | | | | | |
| Цифрлы технологиялар белән эшләү буенча яңадан әзерлек узган авыл хуҗалыгы предприятиеләре белгечләре өлеше (авыл хуҗалыгы предприятиеләрендә эшләүче белгечләрнең гомуми санынnan процентта) | | | | | | | | | |
| База | 6,0 | 10,0 | 15,0 | 20,0 | 25,0 | 30,0 | 35,0 | 40,0 | 45,0 |
| Максатчан | 6,0 | 10,0 | 20,0 | 25,0 | 30,0 | 35,0 | 40,0 | 50,0 | 50,0 |
| Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең мөгезле эре терлек санын көтү | | | | | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| белән идарә итү программалары белән колачлау, процент | | | | | | | | | |
| База | - | 15,0 | 18,0 | 20,0 | 25,0 | 30,0 | 35,0 | 40,0 | 45,0 |
| Максатчан | - | 15,0 | 18,0 | 20,0 | 25,0 | 30,0 | 35,0 | 40,0 | 50,0 |
| Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең мөгезле эре терлек санын азык ашату белән идарә итү программалары белән колачлау, процент | | | | | | | | | |
| База | - | 15,0 | 18,0 | 20,0 | 25,0 | 30,0 | 35,0 | 40,0 | 45,0 |
| Максатчан | - | 15,0 | 18,0 | 20,0 | 25,0 | 30,0 | 35,0 | 40,0 | 50,0 |
| Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең үсемлекчелегендә исәп-хисап алып бару программалары белән колачланган сөрү җирләре мәйданнары өлеше, процент | | | | | | | | | |
| База | - | - | 4,4 | 10,0 | 15,0 | 20,0 | 30,0 | 40,0 | 50,0 |
| Максатчан | - | - | 4,4 | 10,0 | 15,0 | 20,0 | 30,0 | 40,0 | 50,0 |
| Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләрендә техника һәм авыл хуҗалыгы машиналарын навигация системалары белән җиһазландыру өлеше, процент | | | | | | | | | |
| База | - | - | 30,0 | 32,0 | 35,0 | 40,0 | 45,0 | 50,0 | 55,0 |
| Максатчан | - | - | 30,0 | 32,0 | 35,0 | 40,0 | 45,0 | 50,0 | 55,0 |
| Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләрендә техника һәм авыл хуҗалыгы машиналарын автопилот системасы белән җиһазландыру өлеше, процент | | | | | | | | | |
| База | - | - | 20,0 | 22,0 | 25,0 | 30,0 | 35,0 | 40,0 | 45,0 |
| Максатчан | - | - | 20,0 | 25,0 | 30,0 | 35,0 | 40,0 | 45,0 | 50,0 |
| Савым рутинасын контрольдә тоту өчен савым залларына ясалма интеллектны кулланышка кертү өлеше, процент | | | | | | | | | |
| База | - | - | 0,01 | 0,1 | 0,2 | 1,0 | 5,0 | 10,0 | 15,0 |
| Максатчан | - | - | 0,01 | 0,1 | 0,2 | 1,0 | 10,0 | 15,0 | 20,0 |
| Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләрендә хайваннарның аксавын билгеләү өчен ясалма интеллектны кулланышка кертү өлеше, процент | | | | | | | | | |
| База | - | - | 0,01 | 0,1 | 0,2 | 1,0 | 5,0 | 10,0 | 15,0 |
| Максатчан | - | - | 0,01 | 0,1 | 0,2 | 1,0 | 10,0 | 15,0 | 20,0 |
| Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләрендә мөгезле эре терлекнең туклыклылыгын билгеләү системаларын кулланышка кертү өлеше, процент | | | | | | | | | |
| База | - | - | 0,01 | 0,1 | 0,2 | 1,0 | 5,0 | 10,0 | 15,0 |
| Максатчан | - | - | 0,01 | 0,1 | 0,2 | 1,0 | 10,0 | 15,0 | 20,0 |
| Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләрендә мөгезле эре терлекнең аулануын билгеләү системаларын (педометрлар / муенсалар / болюслар) кулланышка кертү өлеше, процент | | | | | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| База | - | - | 15,0 | 20,0 | 25,0 | 30,0 | 35,0 | 40,0 | 45,0 |
| Максатчан | - | - | 20,0 | 25,0 | 30,0 | 35,0 | 40,0 | 45,0 | 50,0 |
| Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексының дәүләт мәгълүмат системасында авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре өлеше, процент | | | | | | | | | |
| База | 15,0 | 20,0 | 22,5 | 25,0 | 27,5 | 30,0 | 35,0 | 45,0 | 50,0 |
| Максатчан | 15,0 | 20,0 | 25,0 | 30,0 | 35,0 | 40,0 | 45,0 | 55,0 | 65,0 |
| 6 нчы стратегик бурыч. Финанслар һәм иминият: Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексының финанс тотрыклылыгын һәм инвестицион җәлеп итүчәнлеген арттыру | | | | | | | | | |
| 2022 ел дәрәҗәсенә карата авыл хуҗалыгында төп капиталга инвестицияләр арту темпы (чагыштырма бәяләрдә), процент | | | | | | | | | |
| База | 100,0 | 100,0 | 101,9 | 103,8 | 105,8 | 107,8 | 109,8 | 111,9 | 114,1 |
| Максатчан | 100,0 | 100,0 | 101,9 | 104,0 | 106,2 | 108,4 | 111,7 | 115,2 | 118,7 |
| 2022 ел дәрәҗәсенә карата азык-төлек продуктлары һәм эчемлекләр җитештерүдә төп капиталга инвестицияләр арту темпы (чагыштырма бәяләрдә), процент | | | | | | | | | |
| База | 100,0 | 119,1 | 122,1 | 125,3 | 128,6 | 131,9 | 135,4 | 138,9 | 142,5 |
| Максатчан | 100,0 | 119,1 | 122,7 | 127,1 | 131,5 | 140,7 | 154,8 | 170,3 | 187,3 |
| Авыл хуҗалыгы оешмаларының рентабельлелеге (субсидияләрне исәпкә алып), процент | | | | | | | | | |
| База | 11,7 | 5,8 | 10,2 | 10,5 | 10,6 | 10,6 | 12,3 | 12,8 | 13,1 |
| Максатчан | 11,7 | 5,8 | 10,2 | 15,1 | 15,4 | 20,0 | 21,3 | 23,2 | 25,0 |
| Күпьеллык утыртмалар чәчүлекләренең һәм утыртуларның гомуми мәйданында күпьеллык утыртмаларның иминләштерелгән чәчүлек мәйданнары һәм утыртуларның чагыштырма авырлыгы, процент | | | | | | | | | |
| База | 13,3 | 19,0 | 20,0 | 22,8 | 23,2 | 23,8 | 24,4 | 24,8 | 25,0 |
| Максатчан | 13,3 | 19,0 | 21,0 | 22,0 | 23,0 | 25,0 | 26,0 | 28,0 | 30,0 |
| Баш санының гомуми күләмендә мөгезле эре терлекнең иминләштерелгән баш санының чагыштырма авырлыгы, процент | | | | | | | | | |
| База | 19,6 | 24,0 | 15,0 | 16,0 | 17,0 | 18,0 | 19,0 | 19,0 | 20,0 |
| Максатчан | 19,6 | 24,0 | 25,34 | 27,5 | 28,05 | 28,05 | 28,05 | 28,05 | 28,05 |
| 7 нче стратегик бурыч. Кече хуҗалык итү формалары һәм кооперация: кече һәм урта авыл хуҗалыгы эшкуарлыгы өлкәсендә нәтиҗәле мәшгульлекне арттыру һәм Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексында кече хуҗалык итү формалары тарафыннан җитештерелә торган авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү һәм сату күләмнәрен арттыруга юнәлдерелгән кооперация элемтәләрен үстерү | | | | | | | | | |
| Кече һәм урта авыл хуҗалыгы эшкуарлыгы һәм кулланучылар | | | | | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| кооперациясе өлкәсендә (крестьян (фермер) хуҗалыкларын һәм шәхси ярдәмче хуҗалыкларны да кертеп) мәшгульләр саны, мең берәмлек | | | | | | | | | |
| База | 52,1 | 56,1 | 60,4 | 64,6 | 68,8 | 73,1 | 77,3 | 81,6 | 86,1 |
| Максатчан | 52,1 | 57,1 | 62,7 | 68,3 | 73,9 | 79,5 | 85,1 | 90,8 | 97,1 |
| Булдырылган авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары саны (арта бара торган йомгак белән), берәмлек | | | | | | | | | |
| База | 320,0 | 340,0 | 360,0 | 380,0 | 400,0 | 420,0 | 440,0 | 460,0 | 480,0 |
| Максатчан | 320,0 | 345,0 | 370,0 | 395,0 | 420,0 | 445,0 | 470,0 | 495,0 | 520,0 |
| Авыл торак пунктларында яшәүчеләргә күрсәтелә торган, шул исәптән әзерләү, җитештерү һәм сәүдә эшчәнлеге буенча хезмәтләрнең гомуми күләме, млрд.сум | | | | | | | | | |
| База | 20,4 | 22,4 | 24,1 | 25,9 | 27,9 | 30,0 | 32,2 | 34,6 | 37,2 |
| Максатчан | 20,4 | 22,4 | 24,7 | 27,2 | 29,9 | 32,9 | 36,1 | 39,8 | 43,7 |

2030 елга кадәр Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексын үстерү стратегиясенә 2 нче кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 4 август, 565 нче
карары редакциясендә)

## 2030 елга кадәр Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексын үстерү стратегиясенең I этабын гамәлгә ашыру буенча чаралар планы (2024 – 2026 еллар)

| Т/с | Чараның исеме | Башкару вакыты | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1 нче стратегик бурыч. Эшкәртү: сыйфатлы һәм таләп ителә торган азык-төлек продуктларын, шулай ук авыл хуҗалыгы чималын һәм икенчел ресурсларны (калдыкларны) эшкәртү барышында алына торган югары өстәлгән кыйммәтле башка продукцияне җитештерү күләмнәрен һәм ассортиментын арттыру | | | |
